| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ФЕДОТОВКА СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ФЕДОТОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2024 елның 1 августы № 19

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның, 26 октябрендәге 9 номерлы (15.10.2018 № 27, от 29.11.2018 №33, от 01.03.2023 № 3, от 10.04.2023 № 11 үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның, 26 октябрендәге 9 номерлы (15.10.2018 № 27, от 29.11.2018 № 33, от 01.03.2023 № 3, от 10.04.2023 № 11 үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац белән тулыландырырга:

«Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы күрсәтмәсе белән раслана торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата 1,2 процент;»;

2) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацларын тиешенчә бишенче һәм алтынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет урамы, 6 йорт, Совет урамы, 8 йорт (СДК бинасы), Кузьминовка авылы, Кооператив урамы, 10 йорт (авыл клубы бинасы) адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә һәм 2025-2027 еллар салым чорларына гамәлдә була.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Федотовка авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе В.И.Павлова

ИНН 1825000454
КПП 164901001